**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7886**
**29.12.2018**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет төзү турында» 2016 елның 10 августындагы 4150 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 42 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет төзү турында» 2016 елның 10 августындагы 4150 нче карарына (Башкарма комитетның 2017 елның 9 июнендәге 3533 нче карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет турында нигезнамәдә:

- 9 пунктның 3 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) аңа хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез рәвештә бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый советлар функциясе йөкләнгән очракта, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез рәвештә бәяләүне (алга таба – хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез рәвештә бәяләү) үткәрү Иҗтимагый совет турындагы нигезнамәгә кертелә.»;

- 10 пунктның 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез рәвештә бәяләү үткәрүгә мөнәсәбәтле оешмалар исемлеген билгели;»;

- 10 пунктның 3 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) кирәк булганда, хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез рәвештә бәяләү критерийларын билгели (федераль законнар белән билгеләнә торган гомуми критерийларга өстәмә рәвештә);»;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет составын кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 29 декабрендәге
7886 нчы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты карамагындагы
Иҗтимагый совет составы

| Т/с | Ф.И.А.и. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1 | Гусева Татьяна Юрьевна | «Башаккай» 40 нчы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең өлкән тәрбиячесе |
| 2 | Дубравина Светлана Александровна | «Җиләккәй» 70 нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең педагог-психологы |
| 3 | Жестков Эдуард Михайлович | «Әтиләр берлеге» рәисе (килешенү буенча) |
| 4 | Зайцева Валентина Алексеевна | педагогия хезмәте ветераны (килешенү буенча) |
| 5 | Ипеева Райчка Дмитриевна | Яр Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (килешенү буенча) |
| 6 | Львова Роза Алексеевна | педагогия хезмәте ветераны (килешенү буенча) |
| 7 | Манусова Валентина Николаевна | хезмәт ветераны (килешенү буенча) |
| 8 | Миргалимова Мөслимә Гариф кызы | шәһәр ветераннар Советы рәисе урынбасары (килешенү буенча) |
| 9 | Рутковская Любовь Владимировна | хезмәт ветераны (килешенү буенча) |
| 10 | Фәйрушин Әнәс Батыр улы | ТР атказанган мәдәният хезмәткәре (килешенү буенча) |
| 11 | Фәтхуллина Роза Гариф кызы | Яр Чаллы инвалидлар иҗтимагый оешмасының идарә рәисе (килешенү буенча) |
| 12 | Хәмидуллин Рафаэль Азат улы | «Орион» ЯҮ яшьләр белән эшләү буенча белгече, Яр Чаллы шәһәре шәһәр советы карамагындагы Иҗтимагый яшьләр парламенты рәисе |
| 13 | Холодилова Вероника Николаевна | «Заман» яшьләр үзәге муниципаль автономияле учреждениесенең педагог-оештыручысы |
| 14 | Юлчурина Юлия Викторовна | «Олеся» 20 нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең өлкән тәрбиячесе. |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова